**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Починок Кучук авыл җирлеге башлыгы урынбасары**
**КАРАРЫ**

**2024 елның 31 октябре** **№ 7**

**Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлегенең Иске Кенә авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Починок Кучук авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2024 елның 15 ноябренә 18 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Починок Кучук авыл җирлегенең Ике Кнә авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Иске Кнә авылы, Октябрь урамы, 44А йорты адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Сез 2025 елда Кукмара муниципаль районының Починок Кучук авыл җирлеге Иске Кнә авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 һәм 2 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срокы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктыртуны ремонтлау һәм карап тоту, проект-смета документлары, комплектлау материаллары сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, урам яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре);

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмалары төзү һәм ремонтлау (су суырту манарасын, су саклау зонасын, су белән тәэмин итү челтәрен һәм ул тирәдәге территорияләрне карап тоту, ремонтлау, төзү һәм төзекләндерү, проект-смета документлары, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

- жир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (Иске Кнә авылы чишмәләрен һәм аның тирәсендәге территорияләрне төзекләндерү, төзү һәм карап тоту, проект-смета документлары, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү һәм территорияләрне төзекләндерү буенча башка эш төрләре);

- яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту (яр буе зоналарын чистарту һәм төзекләндерү, проект-смета документлары, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгынга каршы җиһазлар, савытлар, гидрантлар һәм комплектлау материаллары сатып алу, урнаштыру, карап тоту, шул исәптән проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- янгынга каршы резервуарларны (янгын сулыкларын), янгын пирсларын урнаштыру, ремонтлау (гидротехник корылмаларны (Синерь буасын) ремонтлау, төзекләндерү һәм карап тоту, янгын сүндерү техникасына гидротехник корылмаларга (Синерь буасына) керү өчен мәйданчыкны төзекләндерү, проект-смета документлары һәм техик күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш өчен түләү, гидротехник корылмаларны ремонтлау, төзекләндерү һәм тоту буенча башка эш төрләре);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (урам юл челтәрен карап тоту, җиһазлар, запас частьләр сатып алу, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү),

(урам юлларына вак таш салу, вак таш белән юллардагы чокырларны ремонтлау, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү, вак таш салу һәм чокырларны ремонтлау буенча башка төр эшләр),

(зиратка илтә торган юлга вак таш салу һәм чокырларны ремонтлау, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш өчен түләү);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (территорияне төзү, төзекләндерү, тоту һәм җиһазландыру, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, башка эш төрләре),

(массакүләм ял итү урыннарын (парклар, скверлар, спорт мәйданчыклары, мәдәни чаралар уздыру урыннары һәм башка массакүләм ял итү урыннары, хезмәт күрсәтү өчен техника сатып алу) һәм янәшәдәге территорияләрне төзү, тоту, төзекләндерү, җиһазландыру һәм ремонтлау, инвентарь, җиһазлар һәм кече архитектура формаларын сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, ташу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, массакүләм ял итү урыннарын һәм янәшәдәге территорияләрне урнаштыру, тоту, төзекләндерү һәм җиһазландыру буенча башка эш төрләре);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары составына кермәгән җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир асте кичүләрен ремонтлау (җәяүлеләр күперен

һәм янәшәдәге территорияләрне ремонтлау, төзү, тоту һәм төзекләндерү, проект-смета документлары, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

- традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү (авыл зираты территориясен төзекләндерү һәм карап тоту, инвентарь сатып алу, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, зират территориясен төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре)

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

4. Гражданнар җыеннын үткәрүгә җаваплы итеп Починок Кучук авыл җирлеге башкарма комитететын билгеләргә.

5. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Починок-Кучук
авыл җирлеге
башлыгы урынбасары Г.И. Петров

СОВЕТ ПОЧИНОК-КУЧУКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КУКМОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОГРН 1021607752924
ИНН 1623001741